ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УРАЗБАХТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗБАХТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул.Советская, д.1а, с. Уразбахтино,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422155

Совет ур., 1 нче а йорт, Уразбахты авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422155

тел.(факс): (85563) 2-86-36; e-mail: UrBah.Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru


**Постановление** **Карар**

25.03.2025 ел №6

**Хуҗасыз хайваннарны кайтару тыела торган урыннарны һәм хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 №131-ФЗ, "Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 14.07.2022 №269-ФЗ Федераль законнары, Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлеге Уставы нигезедә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару тыела торган урыннар исемлеген әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Уразбахты авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесен хуҗасыз хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында Карар кабул итәргә вәкаләтле зат дип билгеләргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында (http://mamadysh.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче: Р.Г.Шайхутдинов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге
Башкарма комитетының
25.03.2025 ел , №6 карарына
1 нче кушымта

**Уразбахты авыл җирлеге территориясендә хуҗаларыннан башка хайваннарны кайтару тыела торган урыннар исемлеге**

Хайваннарны приютта стерильләштерү, тамгалау, исәпкә алу, карантинлаштыру, дәвалау, вакцинацияләү чаралары тәмамланганнан соң, башка хайваннарга яисә кешегә карата мотивацияләнмәгән агрессивлык күрсәтмәгән очракта, әгәр мондый хайваннарны приютларда, территориядә һәм 500 метрдан якынрак ераклыкта тоту мөмкинлеге булмаса, хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына (тотылган ау урынына) кире кайтару тыелу урыннары:

- авыл җирлеге хакимияте,

- социаль өлкә учреждениеләре;

- сәламәтлек саклау объектлары;

- мәгариф учреждениеләре (мәктәпләр, балалар бакчалары);

- мәдәният объектлары;

- балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыклары;

- җәмәгать территорияләре (бакчалар, парклар, скверлар, торак пунктларның урамнары, мәйданнары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буе полосалары);

- площадок для проведения массовых мероприятий;

- стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннары, сәүдә нокталары территорияләре;

- зиратлар һәм мемориаль зоналар.